РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2024 Буа шәһәре № 315 Бк/к

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап палатасы рәисенең, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 110/Бк/к номерлы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 елның 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап палатасы рәисенең, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 110/Бк/к номерлы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (ТР Буа

муниципаль районы Башкарма комитетының 15.08.2018 №216/ИК-п, 01.11.2018 №343/ИК-п, 30.12.2021 № 412/Бк/к, 07.04.2022 № 93/Бк/к, 20.10.2022 № 314/Бк/к, 13.12.2022 № 391/Бк/к, 24.05.2024 № 137/Бк/к карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «13 323» саннарын «13 990» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 4 нче һәм 5 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырылырга тиеш: https://buinsk.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
24.04.2018 елдан 110/ик-
п номерлы карарына 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
карары редакциясендә
31.10.2024 № 315 Бк/к)

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы рәисен айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(сумнарда)

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| | Дүртенче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 38 889 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 34 998 |
| Депутат | 18 848 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 16 019 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 34 998 |

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
24.04.2018 елдан 110/ик-
п номерлы карарына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
карары редакциясендә
31.10.2024 № 315 Бк/к)

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләмнәре, сумнар | | |
|---|---|---|---|
| | республика әһәмиятендәге шәһәрләр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләрендә | авыл җирлекләрендә | |
| | бишенче төркем | унберенче төркем | уникенче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 35 289 | 20 991 | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 31 759 | 15 085 | 13 991 |
| Депутат | 16 910 | 13 990 | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 14 373 | 13 990 | 13 990 |